УДК 930.271

***В.М. Усманов***

## ХАН ЗИРАТЫ ТАШЪЯЗМАЛАРЫ

Данная статья посвящена исследованию эпиграфического памятника ханского времени близ города Темникова в Мещерском крае, обнаруженного недавно. Владения темниковских татар располагались в бассейне рек Цна и Мокша на современной территории Мордовской Республики. Наряду с царями и царевичами из Чингизидов Касимовского ханства в системе осколков Золотой Орды и мещерских татарских княжеств в этих краях особое положение занимали и темниковские мурзы. Для развития городов, архитектуры и искусства письма по камню в Касимовском ханстве были все предпосылки – древние традиции, центр культуры, наличие сети духовных учебных заведений, связанных с мусульманским миром, и, что немаловажно, существование карьеров известняка на берегах Оки, являющегося одним из лучших материалов для художественного творчества. Изучение, фиксация, реконструкция эпиграфических памятников средневековья в Мещерском крае остается неотложной необходимостью.

**Ключевые слова:** эпиграфика Касимовского ханства, арабописьменные памятники, ханкирманский стиль, почерки сульс, фотодокументация, каллиграфический орнамент, резчики-катибы, месторождения строительного камня

This article is devoted to the study of an epigraphic monument of the Khan’s time near the town of Temnikov in the Meshchera region, which was recently discovered. The possessions of the Temnikov Tatars were located in the basin of the Tsna and Moksha rivers in the modern territory of the Mordovian Republic. Along with the tsars and princes of the Chingizids of the Kasimov Khanate, the Temnikov Murzas held a special position in the system of the remnants of the Golden Horde and the Meshchera Tatar principalities in these regions. The development of cities, architecture, and the art of stone carving in the Kasimov Khanate was facilitated by ancient traditions, a cultural center, a network of religious educational institutions connected with the Muslim world, and, importantly, the availability of limestone quarries on the banks of the Oka River, which is one of the best materials for artistic creation. The study, documentation, and reconstruction of medieval epigraphic monuments in the Meshchera region remain an urgent necessity.

**Keywords:** epigraphy of the Kasimov Khanate, Arabic written monuments, Khankirman style, Suls handwriting, photographic documentation, calligraphic ornamentation, katib carvers, building stone deposits


Мәкаләдә Мордовия Республикасының Темников районы биләмәсендә урнашкан «Хан зираты» кабер ташлары турында сүз барачак. Халык телендә ул каберстанны «Палдеж зираты» дип тә атап йөртәләр. Риваятьләрдә бу изге урын татар ханнары белән бәйләп сөйләнелсә дә, чынлыкта ул хан-солтаннарга нисбәтле түгел. Матбугатта яисә фәнни китапларда әлеге тарихи объект турында белешмәләр юк дәрәҗәсендә. Дөрес, Фәүзия Бәйрәмова хезмәтләрендә аның турында әйтеп үтелә [6; 7]. Галимә болай дип яза: «Шакирҗан

хәзрәт Кутыев исә бу тирәдә ханнар яшәгән, дип бара, аларның зиратлары да биредән 12 чакрымнар ераклыкта икән. “Без иң беренче шул зиратта яткан ханнарның рухы өчен дога кылабыз, – диде ул. – Ул урын “Палдеж зираты” дип атала, элек анда татар авылы булган. Бер ханның хәтта аяк очына атын да күмгәннәр, башка кабергә, әлбәттә... Ул зиратта бер генә хан күмелмәгән, дип сөйлиләр иде...”» [6: 36]. Башка язма чыганакларда бу зиратка кагылышлы мәгълүмат очрамады.

Күренекле рәссам-хаттат Нәҗип Нәкъкаш әйтүенчә, илле ел элек бер төркем Казан студентлары Мордовиядәге татар авылларына оештырылган экспедицияләр вакытында, җирле кардәшләребез Татарстан кунакларын Түмән каласы белән Тархан арасындагы изге урынга – борынгы мазарстанга алып баралар. Һәм шул вакытта зират уртасында Шәһре Болгардагы затлы китабәләргә (эпитафияләргә) охшаш ике метр чамасы биеклектәге, куфи язулы, рельефлы бишалты һәм аның янәшәсендә дистәләгән кечерәк ташъязмалар булган. Ләкин бүгенге көндә алар сакланмаган.

2025 елда бу төбәккә оештырылган фәнни экспедиция вакытында Карай авылы кешесе Рафик хәзрәт мәкалә авторын шушы борынгы зиратка алып барды. Чынлап та, калкулык битендә урнашкан мазарстанда ике тимер чардуганнан башка бернинди ташъязмаларның булмавы ачыкланды (1 нче рәсем). Шуңа да карамастан бу тарихи объектны җентекләп карап-тикшереп чыгарга кирәк дип таптык, һәм эш барышында бер урында җирдән калкып торган кечкенә таш кисәге игътибарны җәлеп итте. Беренче караштан ук аның XVI гасыр азагы – XVII гасыр башына нисбәтле кабер ташы булуы аермачык күренеп тора иде. Беренчедән, тимпан өлешендәге ислими дип аталган үзенчәлекле үсемлек бизәкләре, текст кырларындагы тасма рәвешендә сузылган чәчәк орнаментының үзенчәлекле төре фәкать Ханкирмән (Касыйм шәһәре) осталарының эшләрендә генә очрый (чагыштыру өчен 1 нче һәм 2 нче рәсемнәргә игътибар итегез); икенчедән, палеографиягә нисбәтле гарәп хәрефләренең формалары (мәсәлән, «дәл»нең очланып өскә каратып тәмамланган өлешләре) биредәге хаттатларның гына язу рәвешенә хас) һәм, шулай ук, – башка яклардагы (мәсәлән, Казан ханлыгы) үрнәкләреннән аермалы буларак, «Гыймран» сүрәсендәге 59 нчы аятьнең Касыйм һәм Түмән (хәзерге Мордовия Республикасындагы Ука елгасының уң як ярында урнашкан Темников шәһәре) китабәләрендә генә урын алуын әйтергә кирәк. М. Әхмәтҗанов мәкаләләренең берсендә әйтелгәнчә, Касыйм ташъязмаларының «...күпчелеге Казан ядкәрләрендә очрамаган дини формула белән башлана. Бу формула түбәндәге мәгънәдән гыйбарәт: “Аллаһы Тәгалә өчен Гайсә Адәм галәйһиссәләм белән бер дәрәҗәдә”» булуын әйтә [4].

Тикшерү барышында бу ядкәр янәшәсендә җирдә тагын дистәгә якын эпитафия фрагменты табылды, фотога төшерелде һәм документлаштырылды. Шулай итеп, бу табыш Нәҗип Нәкъкашның




1 нче рәсем. Кабер ташының алгы һәм сул ян ягының күренеше




2 нче рәсем. Кабер ташының арткы һәм уң ян ягының күренеше

сүзләрен раслаучы кире кагып булмастай ышанычлы дәлил булып чыкты.

Шунысы кызганыч: тарих өчен гаять кыйммәтле бу истәлекләрне, 90 нчы еллар башында булса кирәк, махсус ваткалап, ашыгыч рәвештә төзү материалы буларак ташып бетергәннәр, дип сөйлиләр.

Без Алтын Урда дәүләтенең беренче пайтәхете Мукшы (Наручат) я булмаса Ханкирмән, Сарыкылыч һәм шуннан ерак түгел Мукшы елгасының уң як ярында урнашкан Төмән-Кала (Темников) шәһәрләре турында төрле китаплардан укып һәм ишетеп беләбез [1; 2; 3; 11]. Мәсәлән, хан сарайлары, җамигъ мәчетләр, таштан салынган мәһабәт биналар, төрбә-мунчалар кебек затлы корылмалар һ. б. хакында мәгълүматыбыз шактый. Шулай ук Х. Фәезханов һәм В. Вельяминов-Зерновның фәнни хезмәтләрендә Касыйм ташъязмалары турында язылган [8; 10]. Ләкин Урта гасырларга караган әлеге ядкәрләрнең бик азы гына безнең көннәргә кадәр сакланып калган. Шуларның берсе – Төмән каласы белән янәшә генә урнашкан Хан зиратындагы бүгенгәчә җәмәгатьчелеккә мәгълүм булмаган борынгы кабер ташы фрагментлары.

Укучылар игътибарына ташъязманың өлешчә укылышын тәкъдим итәбез:

Алгы ягында (калку язулы):

| Текст | Укылышы |
|---|---|
| قال الله تبارک و تعالی ان مثل عیسی | [Калә Аллаһу Тәбарәк вә Тәгалә: «Иннә мәсәлә Гыйса] |
| ...عند الله | [гыйнда Аллаһи] кәмәсәли адәмә халәкаһү мин тораби сөммә калә ләһү күн фәйәкүнү»[1] («Гыймран» сүрәсе, 59 нчы аять) |
| .......... | ......... |
| کون... | .......... көн |
| .......... | .................. |
| الاکرام... | .......... әл-әкрам |
| .......... | .................. |

Арткы ягында (калку язулы):

| Текст | Укылышы |
|---|---|
| ...بو لوحنی | Бу ләүхәне … (улы өчен) |
| بنا قیلدوردی...اناسی | (мәрхүмнең әнисе …бина кылдырды |
| .......... | … |

Ташъязма ядкәрнең ян кырларында «Бәкара» сүрәсенең 255 нче аяте («Аятелкөрси») язылган.

Шулай итеп, фәнни экспедиция барышында татар эпиграфикасында моңа кадәр теркәлмәгән һәм документлаштырылмаган истәлек табылды. Һәм халкыбыз яшәгән төрле төбәкләрдәге, шул исәптән Мукшы, Төмән, Касыйм якларындагы эзләнүләр яңа табышларга һәм ачышларга китерер дип өметләнәбез.

**Әдәбият**

1. *Агеев В.В.* Касимовский мусульманский некрополь: история и перспективы изучения // Древности Поочья: Сб. науч. работ к 60-летию В.В. Судакова / сост.: А.А. Гомзин, В.И. Завьялов, И.Г. Кусова; отв. ред. А.О. Никитин. Рязань: РИКО, 2016. С. 264–274.

2. *Агеев В.В.* Надгробия касимовских татар как исторический источник // XI Фаизхановские чтения: Ислам в Рязанской области: прошлое, настоящее и будущее: материалы XI Всерос. науч.-практ. конф., г. Рязань, 14 апреля 2015 г. М., 2016. С. 85–89.

4. *Әхмәтҗанов М.И.* Касыйм шәһәрендәге татар дөрбәләре // Татар археологиясе. 2006. № 1–2 (16–17). Б. 197–217, ил. белән. URL: http://www.misharlar.ru/ahmetzyanov.htm (мөрәҗәгать итү көне: 04.03.2026).

---

[1] *Калә Аллаһу Тәбарәк вә Тәгалә: «Иннә мәсәлә Гыйсаи гыйнда Аллаһи кәмәсәли адәмә халәкаһү мин тораби сөммә калә ләһү күн фәйәкүнү»* – «Гайсәнең мисалы Аллаһ хозурында Адәм (галәйһиссәлам) кебек. Адәмне туфрактан яралтты да соңра аңа: «Бул», диде, Адәм бар булды. (Гайсә дә Аллаһуның: «Бар бул», – дип әйтүе белән булды).

5. *Әхмәтҗанов М.И.* XVII–XVIII гасыр татар ташбилгеләре. Казан, 2011.

6. *Бәйрәмова Ф.Ә.* Ачылмаган татар тарихы. Казан, 2011.

7. *Бәйрәмова Ф.Ә.* Мишәр иленең татар авыллары // Туган җир. 2021. № 3. Б. 36.

8. *Вельяминов-Зернов В.В.* Исследования о Касимовских царях и царевичах: в 4 частях. СПб.: тип. Императорской Академии Наук. – Ч. I. 1863; Ч. II. 1864; Ч. III. 1866.

9. *Еникеев С.Х.* Очерк истории татарского дворянства. 2-е изд., стер. Уфа: Гилем, 2007. 352 с.

10. *Усманов М.А.* Заветная мечта Хусаина Фаизханова. Казань: Татар. кн. изд-во, 1980. 223 с.

11. *Фахрутдинов Р.Г.* Мелодия камней. Казань: Татар. кн. изд-во, 1986. 224 с.

***Усманов Венер Мөдәррис улы,***
*ТР ФА Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият*
*һәм сәнгать институтының Язма мирас үзәге*
*фәнни хезмәткәре*

***Усманов Венер Мударрисович,***
*научный сотрудник Центра письменного наследия*
*Института языка, литературы и искусства*
*им. Г. Ибрагимова АН РТ*
*v.m.usmanov@mail.ru*